**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXXVI СЕССИЯ**

# КАРАР № 4

Наратлы авылы 20.05.2019 ел

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**«Нартлы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр**
**һәм өстәмәләр проекты турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 17 маддәсенең 1 пунктының 1 аспункты һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 35 маддәсенең 1 пунктының 1 аспункты нигезендә

**Наратлы авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына тәкъдим ителүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын беренче укуда кабул итәргә (Кушымта 1).
2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә.
3. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының « Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

1) Дмитриев Сергей Александрович - эшче төркем җитәкчесе;
2) Малышев Сергей Михайлович - эшче төркем әгъзасы;
3) Антонова Елена Николаевна - эшче төркем әгъзасы.

4. Нaратлы авыл җирлеге Советы депутатларының әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча тәкъдимнәре 28.05.2019 елның кадәр эшче төркемгә кертелә дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына тәкъдим ителгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча гражданнар тәкъдимнәре язма рәвештә авторның исем-фамилиясен, туган елын, адресын күрсәтеп, эшче төркемгә түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Нaратлы авылы, Совет урамы, 65А йорт, Нaратлы авыл җирлеге Советы башлыгы Дмитриев Сергей Александровичка.

6. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының « Нaратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны 30.05.2019 елның 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Нaратлы авылы, Совет урамы, 28а йорт (авыл мәдәният йорты).

7. Гавами тыңлауларны Нaратлы авыл җирлеге Советының 14.02.2019 елның булып узган 1 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Нaратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәсе һәм гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе нигезендә үткәрергә (2нче һәм 3нче кушымталар).

8. Эшче төркемгә «Нaратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән Нaратлы авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, Уставны эшләп бетерергә һәм аны 2019 елның 20 июненә кадәр Нaратлы авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

9. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Нaратлы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы С.А.Дмитриев.**

Кушымта 1
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Наратлы авыл җирлеге Советының
XXXXXVI сессиясенең
4 карарына
20.05.2019 ел

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына тәкъдим ителгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты**

| *Гамәлдәге редакция* | *Яңа редакция* |
|---|---|
| **7 маддә. Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре** | |
| *1 бүлекнең 9 пункты:*<br>«9) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру | *1 бүлекнең 9 пунктын яңа басмада бәян итәргә:*<br>«9) Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук Җирлек чикләрендә урнашкан махсус саклана торган табигать территорияләре урманнарын, урманнарны куллануны, саклауны, яклауны, торгызуны оештыру»<br>*(29.12.2017 №463-ФЗ Федераль закон)* |
| | *Түбәндәге басмадагы яңа 2-6 бүлекләр белән тулыландырырга:*<br>«2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Җирлек бюджетыннан Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә, үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру турында килешүләр төзергә хокуклы.<br>3. Аерым дәүләт вәкаләтләрен Җирле үзидарә органнарына бирү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.<br>Җирлек җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә, бу максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә, бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырган өчен җаваплы.<br>Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру дәүләт контролендә тора. Аерым дәүләт вәкаләтләрен Җирле үзидарә органнары |

| | |
|---|---|
| | тарафыннан гамәлгә ашыруны контрольдә тоту шартлары һәм тәртибе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.<br>Наратлы авыл җирлеге Советы үз вәкаләтләре чикләрендә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Җирлек җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану очракларын һәм тәртибен билгеләргә хокуклы.<br>4. Наратлы авыл җирлеге башкарма комитеты чираттагы финанс елына авыл җирлеге бюджетын төзү һәм аның үтәлеше турында хисап төзү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының финанс органы белән килешү төзергә хокуклы.<br>5. Наратлы авыл җирлеге башкарма комитеты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән Җирлек бюджетының касса үтәлеше буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә хокуклы.<br>6. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары, Наратлы авыл җирлеге Советы тарафыннан әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруда катнашу хокукын гамәлгә ашыру турында Карар кабул ителгән очракта, федераль законда билгеләнгән тәртиптә үзләренә тапшырылмаган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашалар.» |
| **8 маддә. Җирлек җирле үзидарә органнарының Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән сорауларын хәл итүгә хокуклары** | |
| *1 бүлекнең 12нче пункты:*<br>«12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны тормышка ашыру;» | *1 бүлекнең 12нче пунктын түбәндәге басмада бәян итәргә:*<br>«12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарга мөнәсәбәттә эшчәнлекне гамәлгә ашыру;»<br>*(27.12.2018 N 498-ФЗ Федераль закон)* |
| **19 маддә. Территориаль иҗтимагый үзидарә** | |
| *3 бүлек:*<br>«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре, Җирлек Советы тарафыннан, әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча билгеләнә.» | *3 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:*<br>«3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре тиешле территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча, Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә.»<br>*(27.12.2018 №556-ФЗ Федераль закон)* |

| | |
|---|---|
| *Түбәндәге басмада яңа 4.1 пункты белән тулыландырырга:*<br>«4.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәгән вакыттан алып, тиешле җирлекләрнең, муниципаль районның җирле үзидарә вәкаләтле органы булып санала. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе муниципаль берәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы норматив хокукый актлары белән билгеләнә.»<br>*(27.12.2018 №556-ФЗ Федераль закон)* | |
| **22 маддә. Гавами тыңлаулар** | |
| | **22 маддә. Гавами тыңлаулар, фикер алышулар**<br>*(29.12.2017 №455-ФЗ Федераль закон)* |
| *10 бүлек:*<br>«10. Халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе Җирлек Советы тарафыннан расланган халык тыңлаулары турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.» | *10 бүлекне яңа басмада бәян итәргә:*<br>«10. Әлеге маддәнең 3нче өлешендә күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы һәм (яисә) Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль берәмлек халкына гавами тыңлаулар үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән үз вакытында танышуны, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларда катнашуын тәэмин итүче башка чараларны, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнешен дә кертеп, тыңлаулар нәтиҗәләрен халыкка игълан итүне (бастырып чыгаруны) күздә тотарга тиеш.»<br>*(29.12.2017 №455-ФЗ Федераль закон)* |
| **53 маддә. Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләре** | |
| *2 бүлекнең 12 пункты:*<br>«12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны тормышка ашыру;» | *2 бүлекнең 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:*<br>«12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны тормышка ашыру;»<br>*(27.12.2018 №498-ФЗ Федераль закон)* |
| **73 маддә. Муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү (бастырып чыгару) һәм аларның үз көченә керү тәртибе** | |
| *3 бүлекне түбәндәге эчтәлекле яңа абзац белән тулыландырырга:*<br>«Муниципаль хокукый актларны, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне халыкка игълан итү (бастырып чыгару) тәртибе Җирлек Уставы белән билгеләнә һәм федераль закон белән чикләнә торган муниципаль хокукый актлардан яки аерым нигезләмәләрдән тыш, танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.»<br>*(18.04.2018 №83-ФЗ Федераль закон)* | |

Кушымта 2
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Наратлы авыл җирлеге Советының
XXXXXVI сессиясенең
4 карарына
20.05.2019 ел

**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**XXXXXIV СЕССИЯ**

**КАРАР 1**

Наратлы авылы 14.02.2019 2019 ел

**«Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Наратлы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү**
**тәртибе турында» Нигезләмә хакында**

---

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән №131-ФЗ Федераль законның 28нче маддәсе, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22нче маддәсе нигезендә һәм «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең муниципаль хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашу хокукларын тәэмин итү максатларында

**Наратлы авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне расларга (Кушымта 1).

2. «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Наратлы авыл җирлеге Советының 2011 елның 1 сентябрьндә булып узган IX сессиясендә кабул ителгән 1 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Наратлы авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы С.А.Дмитриев.**

Кушымта 1
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Наратлы авыл җирлеге
Советының XXXXXIV
сессиясенең 1 карарына
20.05.2019 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели (алга таба – ачык тыңлаулар).

1.2. Ачык тыңлаулар Наратлы авыл җирлеге Советы, Наратлы авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан муниципаль берәмлек Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турындагы хисап проекты, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен үткәрелә.

1.3. Гражданнар тыңлауларны үткәрү инициативасын инициатив төркем аша гамәлгә ашыра, ул җирле үзидарә органнарына сайлауларда актив сайлау хокукына ия «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкы арасыннан формалаша.

## 2. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

2.1. Ачык тыңлаулар халык, Наратлы авыл җирлеге Советы, Наратлы авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелә.

Наратлы авыл җирлеге Советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Наратлы авыл җирлеге Советы тарафыннан, ә

Нaратлы авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелүчесе Наратлы авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2.2. Халык тыңлауларына чыгарга тиеш:

1) « Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү муниципаль хокукый акты проекты, Уставка үзгәрешләр бары тик Уставта беркетелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм аларны хәл итү вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга туры китерү максатларында гына кертелә торган очраклардан тыш;

2) «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген үзгәртеп кору турында мәсьәләләр»;

4) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты.

2.3. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар, законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очраклардан тыш, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап проекты, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә, тиешле орган яисә муниципаль берәмлекнең вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль берәмлек Уставы проекты каралганчыга кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

2.4. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар, гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәләләрне күрсәтеп, муниципаль берәмлек Уставы проектын, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проектын, җирлек бюджеты проектын һәм аның үтәлеше турында хисап, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турында мәсьәләләр буенча гавами тыңлаулар уздыру урынын һәм вакытын күрсәтеп, законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очраклардан тыш, 5 көннән дә соңга калмыйча бастырылып чыгарылырга тиеш.

2.5. Устав проекты, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, аларны карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, Наратлы авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән әлеге Устав проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, күрсәтелгән муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аның фикер алышуында гражданнарның катнашу тәртибен рәсми игълан итәргә тиеш (2нче Кушымта).

2.6. Наратлы авыл җирлеге Советының халык алдында тыңлаулар билгеләү турындагы карарында күрсәтелә:

1) ачык тыңлаулар темасы;

2) ачык тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты, урыны;

3) ачык тыңлауларны үткәрү буенча махсус төзелгән комиссия яки эш төркеме составы.

## 3. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ОЕШТЫРУ ТӘРТИБЕ

3.1. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан (алга таба - ачык тыңлауларны оештыручы) гамәлгә ашырыла.

3.2. Ачык тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү процессын ачык тыңлауларны оештыручы тәэмин итә:

- ачык тыңлауларда катнашучыларның башлангыч составын билгели;
- чыгышлар әзерләргә кирәк булган мәсьәләләр исемлеген билгели;
- ачык тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча докладчыларның башлангыч составын билгели;
- ачык тыңлаулар үткәрү регламентын билгели;
- халык алдында тыңлаулар өчен чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җыюны гамәлгә ашыра;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча кирәкле белешмә материаллар, йомгаклау документлары проектларын әзерли;
- ачык тыңлаулар беркетмәсен алып баруны тәэмин итә;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр әзерләүне оештыра;
- ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмәне халыкка җиткерүне тәэмин итә.

3.3. «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге халкы ачык тыңлаулар үткәрү турындагы карар игълан ителгән көннән алып, аларны үткәрү көненә кадәр, Наратлы авыл җирлеге башлыгына ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән муниципаль хокукый актның гавами тыңлауларына чыгарыла торган төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Наратлы авыл җирлеге Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, мәгълүмат итеп, халык тыңлауларында катнашучыларга җиткерелә.

## 4. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРДА КАТНАШУЧЫЛАР

4.1. Гавами тыңлауларда катнашырга чакырыла ала:

- депутатлар;

- дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре;

- эшчәнлекләре фикер алышына торган тема белән бәйле булган оешма, предприятие, учреждение җитәкчеләре яки вәкилләре;

- экспертлар;

- сәяси партияләрнең төбәк һәм җирле бүлекләре, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре;

- массакүләм мәгълүмат чаралары;

- «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче гражданнар.

4.2. Халык тыңлауларында үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән, халык тыңлауларын оештыручыга ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар биргән гражданнар катнаша.

## 5. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫ ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Ачык тыңлаулар утырышлар формасында үткәрелә.

5.2. Гавами тыңлауларда рәислек итүче җирлек Башлыгы булырга мөмкин.

5.3. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул катнашучыларга ачык тыңлауларның темасы, ачык тыңлаулар үткәрүнең тәртибе турында хәбәр итә.

5.4. Рәислек итүче ачык тыңлаулар алып бара һәм көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу тәртибен күзәтә.

5.5. Рәислек итүче чират тәртибендә төп докладчыга (өстәмә докладчыга), шулай ук чыгыш ясарга теләк белдергән башка ачык тыңлауларда катнашучыларга чыгыш ясау өчен сүз бирә.

5.6. Чыгышның вакыты, чыгыш ясаучылар саныннан һәм халык тыңлаулары үткәрү өчен билгеләнгән вакытлардан чыгып, рәислек итүче тарафыннан билгеләнә.

Рәислек итүче чыгыш ясаучылар санына карап, халык тыңлауларында катнашучыларның чыгыш вакытын чикләргә хокуклы.

5.7. Рәислек итүче ачык тыңлауларда тәнәфес игълан итәргә хокуклы.

5.8. Ачык тыңлауларда катнашучының чыгышы тәмамланганнан соң яки чыгыш ясау өчен бирелгән вакыт узгач, рәислек итүче ачык тыңлауларның башка катнашучыларына чыгыш ясаучының позициясе һәм (яки) аргументлары буенча төгәлләштерүче сораулар бирү һәм сорауларга җаваплар өчен өстәмә вакыт бирү мөмкинлеге бирә.

5.9. Сораулар язмача да, телдән дә бирелергә мөмкин.

5.10. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары тәмамлангач, рәислек итүче, кирәк булганда, халык тыңлаулары барышында әйтелгән

тәкъдимнәрне ачыклау өчен комиссия яки эшче төркем әгъзаларына сүз бирергә мөмкин.

5.11. Ачык тыңлаулар үткәргәндә тәртип саклау ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

5.12. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларының барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел. Халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында, эшче төркем рәисе ачык тыңлаулар үткәрү урыныннан китүне таләп итәргә хокуклы.

## 6. АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН РӘСМИЛӘШТЕРҮ

6.1. Ачык тыңлаулар вакытында беркетмә алып барыла. Ачык тыңлаулар беркетмәсендә ачык тыңлаулар үткәрүнең датасы һәм урыны, ачык тыңлауларда катнашучылар саны, Рәиснең, Секретаренең һәм комиссиянең башка әгъзаларының фамилияләре, докладчының (өстәмә докладчы) һәм ачык тыңлауларда башка катнашучыларның исемнәре, докладының кыскача эчтәлеге яки чыгышының кыскача эчтәлеге, башка шартлары чагылдырыла. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма формада бирелә һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә.

Йомгаклау беркетмәсендә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

3) ачык тыңлауларга чыгарылган, әмма аларга кабул ителмәгән мәсьәләләр;

4) ачык тыңлауларда кабул ителгән мәсьәләләр.

6.2. Ачык тыңлаулар беркетмәсе рәислек итүче тарафыннан имзалана һәм аның вәкаләтләре барлык вакыт дәвамында җирлек Советы материалларында саклана, ә бу вакыт узгач, муниципаль архивка саклауга тапшырыла. Муниципаль архивта ачык тыңлаулар материалларын саклау вакыты Наратлы авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм ул дүрт елдан да ким була алмый.

6.3. Халык тыңлауларының нәтиҗәләре ачык тыңлаулар үткәргәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча игълан ителергә тиеш.

6.4. Муниципаль берәмлек Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проектын, авыл җирлеге бюджеты проектын һәм аның үтәлеше турында хисап проектын, муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләрне караучы Наратлы авыл җирлеге Советы сессиясендә комиссия яки эшче

төркем рәисе депутатларга комиссия эше турында, үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында доклад бирә һәм йомгаклау беркетмәсен тәкъдим итә.

3нче кушымта
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
Наратлы авыл җирлеге Советының
XXXXXIV.сессиясенең
1 карарына
20.05.2019 ел

# АЧЫК ТЫҢЛАУЛАРГА ЧЫГАРЫЛА ТОРГАН МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ ҺӘМ «НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ГРАЖДАННАРЫНЫҢ ФИКЕР АЛЫШУДА КАТНАШУЫ

1. «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының муниципаль хокукый актлар проектлары буенча тәкъдимнәре Наратлы авыл җирлеге Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423212, Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Наратлы авылы, Совет урамы, 65а йорт, кушымта итеп бирелә торган үрнәктәге төзәтмәләр таблицасы формасында язма рәвештә:

| *№ т/с* | *Пункт, аспункт* | *Карар проекты тексты* | *Төзәт-мәләр тексты* | *Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты* | *Төзәтмә авторы (Ф.И.О., адрес, эш, уку урыны)* |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр муниципаль хокукый актлар проектларын халыкка игълан иткәннән соң (бастырып чыгару) яки «Интернет» челтәрендә – «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми порталында bugulma.tatar.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет-ресурсында урнаштырганнан соң, бер ай дәвамында эш көннәрендә 8.00–17.00 сәгатьләрдә кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар чыгыш ясаучыларга шәхсән түбәндәге адрес буенча бирелә: 423212, Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы, Наратлы авылы, Совет урамы, 65а йорт.

Гаризалар ачык тыңлаулар үткәрүгә кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8.00 – 17.00 сәгатьләрдә кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре карау өчен махсус төзелгән комиссиягә яисә муниципаль хокукый актлар проектларына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә тапшырыла.